ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/5

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 26 июлендәге «Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 199-ФЗ санлы Федераль закон, 2019 елның 26 июлендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 53 маддәсенә үзгәреш кертү турында» 200-ФЗ санлы Федераль закон, 2019 елның 02 августындагы «Дәүләт (муниципаль) бурыч алулар, дәүләт (муниципаль) бурыч һәм Россия Федерациясе дәүләт финанс активлары белән идарә итүне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Дәүләт һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе һәм алар белән эш итү итү үзенчәлекләре турында» Федераль законның үз көчен югалтуын тану хакында» 278-ФЗ санлы Федераль закон, 2019 елның 02 августындагы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсенә үзгәреш кертү турында» 295-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6, 2015 елның 22 октябрендәге 2/14, 2016 елның 24 февралендәге 6/6, 2017 елның 24 октябрендәге 20/5, 2018

елның 21 февралендәге 23/7, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/5, 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/7 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1)4 маддәнең 12 өлешендәге 7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

2)4 маддәнең 5 өлешендәге 5 пунктта:

«бюджет акчаларының төп администраторлары» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (алга таба - бюджет акчаларының баш администраторлары)»сүзләренә алыштырырга;

«эчке финанс контроле һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3)4.1 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. маддә. Бюджет процессында аерым катнашучыларның эчке финанс аудитын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча бюджет вәкаләтләре.

1. Эчке финанс аудиты – бюджет акчаларының баш администраторының җитәкчесенә, бюджет акчаларын бүлүче җитәкчесенә, бюджет акчаларын алучы җитәкчесенә, бюджет керемнәре администраторы җитәкчесенә, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторы җитәкчесенә алда саналганнарны бирү буенча эшчәнлек булып тора:

1) бюджет акчаларын бүлүченең, бюджет акчаларын алучының, бюджет керемнәре администраторының, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторының (алга таба - бюджет акчалары администраторы), бюджет акчаларының баш администраторының бюджет вәкаләтләрен үтәвен бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат (шул исәптән бюджет хисаплылыгының дөреслеге турында бәяләмә) бирү ;

2) финанс менеджментының сыйфатын күтәрү, шул исәптән бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеген һәм экономиясен арттыру турында тәкъдимнәр бирү ;

3) финанс менеджментының сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән карарларны үтәү нәтиҗәләре турында бәяләмә бирү.

2. Эчке финанс аудиты түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

1) бюджет акчалары баш администраторының, бюджет акчалары администраторының бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган билгеләнгән хокукый актларда, үз бюджет вәкаләтләрен үтәүгә карата таләпләрне (алга таба – эчке финанс контроле) үтәү максатларында гамәлгә ашырыла торган эчке процессның ышанычлылыгын бәяләү һәм эчке финанс контролен оештыру турында тәкъдимнәр әзерләү;

2) бюджет хисабының дөреслеген һәм бюджет исәбен алып бару тәртибенең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.1 маддәсендәге 5 пункты

нигезендә кабул ителгән ведомство (эчке) актларында каралган тәртиптә бюджет хисабын төзү, тапшыру һәм раслау буенча бердәм методологиягә туры килүен раслау;

3) финанс менеджментының сыйфатын күтәрү.

3. Эчке финанс аудиты функциональ бәйсезлек принцибы нигезендә структура бүлекчәләре тарафыннан яисә, эчке финанс аудитының федераль стандартларында каралган очракларда, бюджет акчаларының баш администраторының (хезмәткәрләренең), эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән бюджет чаралары администраторының вазыйфаи затлары (хезмәткәрләре) тврвфыннан гамәлгә ашырыла, әлеге маддәдә каралганча вәкаләтләрне тапшыру очракларында – вәкаләтләрга ия булган бюджет акчаларының баш администраторының (бюджет акчалары администраторының) вәкаләтле вазыйфаи затлары (хезмәткәрләре) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Эчке финанс аудиты эчке финанс аудитының федераль стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Эчке финанс аудитын гамәлгә ашыручы бюджет акчаларының баш администраторлары, бюджет акчалары администраторлары, эчке финанс аудитының федераль стандартлары нигезендә, эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган хокукый актлар кабул итә .

6. Бюджет вәкаләтләрен үтәү сыйфатын, шулай ук активлар белән идарә итү, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу сыйфатын мониторинглауны үз эченә алган финанс менеджменты сыйфаты мониторингын үткәрәләр:

1) финанс органы, үзе билгеләгән тәртиптә, шәһәр бюджеты акчаларының баш администраторларына карата;

2) бюджет акчаларының баш администраторы, үзе билгеләгән тәртиптә, бюджет акчалары администраторларына карата.

7. Финанс менеджменты сыйфаты мониторингы үткәрү тәртибен шул исәптән билгели:

1) финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләрен исәпләү һәм анализлау, күрсәтелгән мониторингны үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны формалаштыру һәм тапшыру кагыйдәләрен;

2) финанс менеджменты сыйфатын мониторинглау нәтиҗәләре турында хисап формалаштыру һәм тапшыру кагыйдәләрен.

8. Шәһәр бюджеты акчаларының баш администраторы Башкарма комитетның финанс органы каравына үзенә буйсынган бюджет акчалары администраторларына карата финанс менеджменты сыйфатына мониторинг үткәрү вәкаләтләрен тапшыру турында тәкъдим кертергә һәм, Башкарма комитетның финанс органы белән килештереп, бу вәкаләтләрне әлеге финанс органына тапшырырга хокуклы.»;

4) 5 маддәнең 10 өлешендәге икенче абзацында «Казна учреждениесе» сүзләреннән соң «аның карамагындагы бюджет акчаларын баш бүлүче белән килешү буенча,» сүзләрен өстәргә;

5) 7 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр Советыының салымнар турында карарларына үзгәрешләр кертү турында карарлары, чираттагы финанс елында һәм план чорында шәһәр бюджеты керемнәрен үзгәртүгә китерә торган һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә керүче бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль хокукый актлар Шәһәр Советына чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары проекты кертелгән көнгә кадәр кабул ителергә тиеш.»;

6)8 маддәдә:

- 12 өлешнең беренче абзацында «Россия Федерациясе территориясендә үстерелгән виноградтан җитештерелгән шәраб продуктлары» сүзләрен «экспорт белән тәэмин итү өчен билгеләнгән алкоголь продукциясе, виноград, күрсәтелгән виноградтан җитештерелгән шәраб продукциясе: шәраб, күбекле шәраблар (шампан шәрабы), якланган географик, эшләнү урыны күрсәткечләре булган ( махсус шәрабләр) ликер шәраблары һәм шәраб чималлары.»;

- 14.1 өлешнең бишенче абзацында «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсендәге 1, 7, 8 пунктларында күрсәтелгән,» сүзләреннән соң «шул исәптән, «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен өстәргә;

7) Түбәндәге эчтәлектәге 11.1. маддәне өстәргә:

«11.1. маддә. Гавами-хокукый берәмлеккә карата акчалата йөкләмәләр.

1. Гавами-хокукый берәмлек алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурыч булып акча средстволары суммасы тора, аны бурычлы зат билгеле бер датага гавами-хокукый берәмлек алдындагы акчалата йөкләмә нигезендә түләргә тиеш.

2. Гавами-хокукый берәмлек алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән төшерү һәм исәпкә кую кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе), Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очраклардан тыш, Башкарма комитетның финанс органы тарафыннан билгеләнә.

3. Гавами-хокукый берәмлек алдында акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) һәм күрсәтелгән йөкләмәләр буенча алыш-бирешләрне исәпкә алу, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләр һәм алыш-бирешләр буенча таләп хокукларын гамәлгә ашыру Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

8) 13 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 маддә. Шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

Шәһәр бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары составына кертелә:

1) номиналь бәясе Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырудан килгән акчалар һәм аларны түләүгә юнәлдерелгән акчалар арасындагы аерма;

2) муниципаль берәмлек тарафыннан Россия Федерациясе валютасында кредит оешмаларынан җәлеп ителгән һәм түләнгән кредитлар арасындагы аерма;

3) шәһәр бюджетына Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетлары тарафыннан бирелеп, муниципаль берәмлек тарафыннан Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән һәм түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

4) тиешле финанс елы дәвамында шәһәр бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү;

5) шәһәр бюджеты кытлыгын финанслауның башка чыганаклары.

2. Шәһәр бюджеты кытлыгын финанслауның башка чыганаклары булып торалар:

1) муниципаль берәмлек милкендәге акцияләр һәм капиталда катнашуның башка формаларын сатудан кергән керемнәр;

2) шәһәр бюджеты акчаларының курс аермасы;

3) муниципаль берәмлек гарантияләрен үтәүгә Россия Федерациясе валютасында җибәрелә торган акча күләме, гарант тарафыннан муниципаль гарантияләрне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә яки бенефициарның принципалга карата таләп хокукы гарантка юл кую белән бәйле очракта;

4) Россия Федерациясе валютасында муниципаль берәмлекнең башка бурыч йөкләмәләрен түләүгә җибәрелә торган акча күләме;

5) шәһәр бюджетыннан юридик затларга бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акча һәм шәһәр бюджетыннан юридик затларга бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма, Россия Федерациясе валютасында;

6) шәһәр бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акча белән шәһәр бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма, Россия Федерациясе валютасында;

7) шәһәр бюджеты акчаларын исәпкә алу барышында бердәм счетта калган акча белән идарә итү буенча операцияләр уздырганда, шәһәр бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәм исәп-хисап счетыннан күчерелгән акчалар һәм шәһәр бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәм исәп-хисап счетына күчерелгән акча арасындагы аерма.

3. Агымдагы финанс елы башына шәһәр бюджеты акчалары:

1) хисап финанс елында файдаланылмаган муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс

елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә, шулай ук Шәһәр Советы карары белән билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплауга һәм, муниципаль контрактлар шартлары нигезендә, агымдагы финанс елында муниципаль берәмлек исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларда күрсәтелгән бюджет ассигнованиеләрен арттыруга, хисап финанс елында аларны бирү финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидия алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә, күрсәтелгән максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары белән каралган очракларда юнәлтелергә мөмкин.

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә бурыч тотрыклылыгының уртача яисә түбән дәрәҗәсе булган бурычка алучылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлек бурыч алуларының гомуми суммасыннан артып китү күләмендә. шәһәр бюджеты кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән чараларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы йомгаклары буенча муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артып киткәндә агымдагы финанс елында муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен киметүче түләүләрне гамәлгә ашыруга юнәлтелә.

4. Шәһәр бюджеты кытлыгын тышкы финанслау чыганаклары составына кертелә:

1) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән һәм муниципаль берәмлек тарафыннан түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

2) муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә, максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән чит ил валютасында муниципаль берәмлек гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акча күләме.»;

9) 14 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 маддә . Муниципаль бурыч

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бурыч йөкләмәләре түбәндәге йөкләмәләр рәвешендә булырга мөмкин:

1) муниципаль берәмлекнең кыйммәтле кәгазьләренә (муниципаль кыйммәтле кәгазьләргә);

2) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан шәһәр бюджетына Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитларына;

3) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитларына;

4) муниципаль берәмлек тарафыннан кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән кредитларга;

5) Россия Федерациясе валютасында билгеләнгән муниципаль берәмлек гарантияләренә (муниципаль гарантияләргә);

6) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясенең чит ил валютасында бирелгән муниципаль гарантияләргә;

7) Россия Федерациясе Бюджет кодексы үз көченә кергәнче барлыкка килгән һәм муниципаль бурычка кертелгән башка бурыч йөкләмәләренә.

2. Муниципаль эчке бурыч күләменә кертелә:

1) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;

2) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан шәһәр бюджетына җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

3) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән һәм муниципаль берәмлек тарафыннан кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча төп бурыч күләме;

4) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;

5) Россия Федерациясе валютасында муниципаль берәмлекнең түләнмәгән башка бурыч йөкләмәләре күләме.

3. Муниципаль тышкы бурыч күләменә кертелә:

1) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында муниципаль берәмлек тарафыннан Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

2) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясе муниципаль берәмлеге тарафыннан чит ил валютасында бирелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме.

4. Муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләре кыска вакытлы (бер елдан кимрәк), уртача вакытлы (бер елдан алып биш елга кадәр) һәм озак вакытлы (биш елдан алып 10 елга кадәр) булырга мөмкин.

5. Әгәр Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәсе муниципаль бурыч йөкләмәсе шартлары белән каралган түләү датасыннан соң килүче датадан соң өч ел эчендә түләүгә тапшырылмаса (йөкләмәләрнең шартлары һәм муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән гамәлләр кредитор тарафыннан башкарылмаса), Шәһәр Советының муниципаль хокукый актларында башкасы каралмаган булса, күрсәтелгән йөкләмә

тулысынча туктатылган дип санала һәм муниципаль бурычтан төшереп калдырыла,

6. Башкарма комитет, әлеге маддәнең 5 өлешендә күрсәтелгән сроклардан соң, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен муниципаль бурычтан төшереп калдыру турында муниципаль хокукый акт чыгара.

7. Муниципаль бурычтан төшереп калдыру, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль бурыч күләмен киметү юлы белән шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларында, исәптән төшерү суммаларын чагылдырмыйча, аларны исәптән төшерү суммасында гамәлгә ашырыла.

8. Муниципаль бурыч белән идарә итү шәһәр Уставы нигезендә Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

9. Муниципаль гарантияләр буенча муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе валютасындагы бурыч йөкләмәләре муниципаль гарантияләрне туктатуга нигез булып торган вакыйгалар (хәлләр) килеп туганда тулысынча туктатылган дип санала һәм күрсәтелгән вакыйгалар килеп туганда (килеп чыгу турында белешмәләр алганда) муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.»;

10) 15 маддәнең 2-7 өлешләрен көчен югалткан дип санарга;

11) 16 маддәне көчен югалткан дип санарга;

12) 17 маддәдә:

- 2.1 өлешнең икенча абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль гарантия биргәндә принципалның финанс хәлен анализлау, тәэминатның җитәрлек булу-булмавын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшерү, шулай ук принципалның финанс хәлен мониторинглау, муниципаль гарантия биргәннән соң бирелгән тәэминатның җитәрлек булу-булмавын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшереп тору Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты яки Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115.2 маддәсендәге 5 пункты нигезендә җәлеп ителгән агент тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

- 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Финанс органы бирелгән гарантияләрнең, алар буенча муниципаль бурычны арттыруның, принципаллар яки өченче затлар тарафыннан гарантияләр белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләренең тулы күләмдә яисә өлешчә муниципаль бурычны киметүнең, принципалларның башка нигездә тулы күләмдә яисә өлешчә йөкләмәләрен туктатуның, бирелгән гарантияләр буенча гарант тарафыннан түләүләрне гамәлгә ашыруның, шулай ук муниципаль гарантияләр белән билгеләнгән башка очракларның хисабын алып бара.»;

- 2, 4, 4.1, 5 өлешләрне көчен югалткан дип танырга;

13) 40 маддәдә:

- икенче абзацта:

«Бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (алга таба - бюджет акчаларының баш администраторлары) сүзләрен «Бюджет акчаларының баш администраторлары» сүзләренә алыштырырга;

«җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

- өченче абзацта «җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

14) 44 маддәдә:

- 1 өлештә:

«Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм башка норматив» сүзләрен «нигезләмәләр» сүзенә алыштырырга;

«,Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлары шартларын, бюджеттан акча бирү турында килешүләрне нигезләүче хокукый актларны (алга таба-килешүләрне) кабул итү» сүзләрен өстәргә;

- 2 өлештә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 3 өлештә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 45 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45 маддә. Муниципаль финанс тикшерүе объектлары

1. Муниципаль финанс тикшерүе объектлары (алга таба – тикшерү объектлары) булып торалар:

1) бюджет акчаларын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар), шәһәр бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);

2) муниципаль учреждениеләр;

3) муниципаль унитар предприятиеләр;

4) Устав (җыелма) капиталларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге катнашкан хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция оешмалары;

5) юридик затлар (Устав (җыелма) капиталларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге катнашкан муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең өлеше булган коммерция оешмаларыннан тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар:

- бюджеттан акча һәм (яки) муниципаль контрактлар бирү турындагы килешүләр нигезендә шәһәр бюджетыннан акча,

муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар алучы юридик һәм физик затлар,

- федераль законнар нигезендә шәхси счетлар ачылган, шәһәр бюджетыннан акча бирү турындагы килешүләрне һәм (яки) муниципаль контрактларны үтәү максатларында төзелгән килешүләрне башкаручылар (тәэмин итүчеләр, подрядчылар)

2. Тикшерү объектлары һәм аларның вазыйфаи затлары муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны үз вакытында һәм тулы күләмдә муниципаль финанс тикшерүе органнарына тапшырырга, муниципаль финанс тикшерүе органнарының вазыйфаи затларына әлеге затларга контроль объектлары территориясендә биналарга һәм корылмаларга керергә рөхсәт бирергә, аларның законлы таләпләрен үтәргә тиеш .»;

16) 46 маддәнең 1 өлешендә «,операцияләрне санкцияләү» сүзләрен төшереп калдырыргаь;

17) 48 маддәне яңа редакциядә бәян итәргә:

«48 маддә. Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча Башкарма комитетның финанс органы вәкаләтләре

1. Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча Башкарма комитетның финанс органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар нигезләмәләренең, шул исәптән бухгалтерлык хисабын һәм муниципаль учреждениеләрнең бухгалтерлык (финанс) хисапларын төзүне һәм тапшыруны билгеләүче нигезләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту;

2) шәһәр бюджетыннан физик затларга башка түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешен, шулай ук шәһәр бюджетыннан акча бирү турында килешүләр (килешүләр), муниципаль контрактлар шартларын үтәүне контрольдә тоту;

3) шәһәр бюджетыннан акча бирү турындагы килешүләрне үтәү максатларында төзелгән килешүләрнең шартларын, шулай ук, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда, муниципаль контрактларны үтәү максатларында төзелгән килешүләрнең шартларын үтәүне контрольдә тоту;

4) бюджет акчаларын (бюджеттан бирелгән акчалар) бирү һәм (яки) алардан файдалану нәтиҗәләре турындагы хисапларның, шул исәптән муниципаль программаларны тормышка ашыру турындагы хисапларның, муниципаль биремнәрнең үтәлеше турындагы хисапларның, шәһәр бюджетыннан акча бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапларның дөреслеген контрольдә тоту.

2. Эчке муниципаль финанс тикшерүе органнары тарафыннан эчке муниципаль финанс тикшерүе вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда:

1) ревизияләр һәм тикшерүләр үткәрелә;

2) контроль объектларына актлар, бәяләмәләр, күрсәтмәләр җибәрелә;

3) финанс органнарына бюджет мәҗбүр итү чараларын куллану турында язмача хәбәрләр җибәрелә;

4) административ хокук бозулар турында законнарда билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турында эшләр башкару гамәлгә ашырыла;

5) тикшерүләр, ревизия һәм тикшерүләр үткәрү өчен кирәкле экспертизалар үткәрү билгеләнә (оештырыла);

6) эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясенең мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында законнары, Россия Федерациясенең дәүләт һәм закон белән саклана торган сер турында законнары нигезендә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалану мөмкинлеге тудырыла

3. Эчке муниципаль финанс тикшерүе органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе Башкарма комитет, шулай ук эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру стандартлары белән билгеләнә.

Эчке муниципаль финанс контроле органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә ревизияләр һәм тикшерүләр уздыру нигезләре һәм тәртибе керә, шул исәптән, аларны уздыру, аларны уздыру вакыты турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле вазыйфаи затлр исемлеге, эчке муниципаль финанс тикшерүе органнары вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары, контроль объектларының (аларның вазыйфаи затларының) хокуклары һәм бурычлары, шул исәптән муниципаль финанс тикшерүе органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырылучы ревизияләрне һәм тикшерүләрне оештыру-техник тәэмин итү керә.

Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру стандартлары Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән эчке муниципаль финанс тикшерүе органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә Башкарма комитет тарафыннан раслана.».

2. Әлеге Карар рәсми бастырылган көненнән үз көченә керә, аерым өлешләренең үз көченә керү вакыты түбәндәгечә билгеләнә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәнең 4.1 маддәсендәге 4 һәм 5 өлешләре; 17 маддәсендәге 2.1 өлешендәге икенче абзацы 2020 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәнең 13 маддәсендәге 3 өлеше 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев